# Нәсыйхәт

җомга
27
апрель
2012 №15

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**


## Яңалыклар

### КОРЪӘН БӘЙГЕСЕНӘ ӘЗЕРЛЕКЛӘР

**Мәдрәсәдә район күләмендә узачак Коръән бәйгесенә әзерлек бара.** Бүгенге көндә авылларда уздырылган ярышның беренче этабы тәмамланды. Әлеге бәйгеләрдә беренчелекне яулаган укучылар 29нчы апрельдә район бәйгесендә катнашачаклар. Биредә җиңүчеләргә бүләкләр һәм грамоталар тапшырылачак. Аннан тыш алар мәдрәсә базасында уздырылачак җәйге җәйләүләрдә дә бушлай ял итә алачаклар.

### ҖОМГА НАМАЗЛАРЫ УКЫТЫЛА

**Мәдрәсә мөгаллимнәре тарафыннан авыл мәчетләрендә җомга намазлары укытыла.** Әлеге чараның максаты – авылларда халыкның дин белән кызыксынуларын арттыру, имамнар белән аралашу, мәдрәсәгә яңа шәкертләр җәлеп итү. Чираттагы җомга Иске Комазан авылы мәчетендә үткәрелде.

### КИҢӘШМӘ

**22нчы март көнне Үзәкләшкән дини оешма–Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте Россия ислам институты бинасында мәдрәсә укытучыларының киңәшмәсе булды.** Анда безнең мәдрәсәнең барлык мөгаллимнәре катнашты.

### КАБУЛ ИТҮ КОМИССИЯСЕ ЭШЛИ

**Мәдрәсәгә укырга керергә теләүчеләр өчен кабул итү комиссиясе эшли.** Биредә уку-укытуга кагылган сорауларга җавап бирәләр, документларны, белешмәләрне кабул итәләр. Белешмәләр өчен телефон: 89172802391, 89093148644

### НАМАЗ ДӘРЕСЛӘРЕ

**Мәдрәсәдә намаз укырга өйрәнү түгәрәге оештырылган.** Аның чираттагысы 18нче апрель көнне үтте. Дәрескә килгән укучылар намазга кагылышлы сорауларын бирә алдылар. Намазда булган җитешсезлекләрен төзәтteләр.

### МӘДРӘСӘДӘ ӨМӘ

**Хезмәткәрләр, укучылар һәм укытучылар мәдрәсә тирәсен җыештыру өмәсендә катнаштылар.** Дөрес, мәдрәсә яны гел карап, чистартылып торганга күрә, пычраклык алай ук күп түгел иде. Бакчадагы агачлар акшарланды, аны узган елгы үләннәрдән арындырдылар, яңа агачлар утыртылды. Мәдрәсә тирәсе тагын да чистарып, хушланып киткәндәй булды. Бу чара үзара дуслыкны тагын да арттырды, бердәмлекне куәтләде.

### КӨМЕШКҮЛДӘ КИЧӘ

**Көмешкүл авыл мәдәният йортында “Яшьләр үзәге” оештыруы астында дини-мәдәни кичә үтте.** Чарага авыл халкы, мәктәп укучылары, мөхтәсибәт һәм мәдрәсә вәкилләре, Казаннан кунаклар килгән иде. Әлеге чара вәгазьләр, бәйгеләр, төрле уеннар белән үрелеп барды. Күңелдә җылы хисләр калды.

### ИГЪЛАН

**“Нәсыйхәт” газетасы ислам тематикасына багышланган “Иң яхшы дини мәкалә” һәм “Иң яхшы дини шигырь” дип аталган конкурс игълан итә.** Җиңүчеләрне истәлекле бүләкләр көтә. Һәр катнашучының иҗади җимешләре безнең газетабызда бастырылачак. Мәкаләләр һәм шигырьләр 30нчы апрельгә кадәр кабул ителәләр. Аларны мәдрәсә электрон почтасына яки хат рәвешендә мәдрәсәгә җибәрергә мөмкин.

**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил ур. 8/28**

# Мәдрәсәбезнең кадерен белик!



**Без бүген җәмгыятебезнең рухи асылын торгызырга, яшәтергә, саклап калырга күп мөмкинчелек тудырылган заманда яшибез. Мамадыш мәдрәсәсенең максаты исә, әлеге рухи мирасны саклап калу һәм киләчәк буыннарга ирештерү, шулай ук югары әхлаклы, дини һәм дөньяви белемнәр белән коралланган, җәмгыятебезнең төрле тармакларында хезмәт итә алырлык белгечләр әзерләү.**

Шунлыктан уку-укыту программасында дини һәм дөньяви фәннәр бергә бәйләнеп Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча укытыла. Бу программалар Татарстан Җөмһүрияте Диния Нәзарәте тарафыннан расланган. Мәдрәсәдә укулар көндезге бүлек шәкертләре өчен 1нче сентябрьдә, кичке һәм ял көне бүлекләре өчен 1нче октябрьдә башлана.

Мәдрәсәнең тагын бер үзенчәлеге бар. Башка мәдрәсә шәкертләренең географиясе бик киң, алар төрле төбәкләрдән килеп укыйлар. Мамадыш мәдрәсәсе җитәкчелеге исә, район башлыгы киңәшен тотып, шәкертләрне катгый үз районыбыздан гына туплый. Әлбәттә, бу ысул авырлыклар тудыра. Чөнки район күләмендә генә мәдрәсәдә укырга теләгән ихласлы укучыларны табу аерата авыр. Әмма әлеге принципка таянып эш итү, районны яшь дини белгечләр белән тәэмин итүдә уңай роль уйнамый калмый. Шәкертләр монда укый һәм бергә яши башлау белән бер гаилә балалары сыман, бер-берсенә ярдәм итеп, әдәпле һәм намуслы булып, бер-берсе турында кайгыртып, ярдәмләшеп яшиләр. Мәдрәсәдә уку-укыту алымнарын камилләштерү, укытучы мөгаллимнәренең педагогик осталыгын күтәрү өстендә даими эш алып барыла, педагогик киңәшмәләрдә тәҗрибә уртаклашу була. Яхшы укучы шәкертләрнең олимпиадаларда катнашу мөмкинлеге булдырылган, Мәдрәсә шәкертләре укудан буш вакытларын файдасыз үткәрмиләр.

**(Дәвамы 2нче биттә)**

# Дин гыйлеме бәхет китерә

**һәр мәктәптә укучы бала зур сыйныфларга якынлашкач, кайсы уку йортына барырга, нинди һөнәр сайларга, кайсы “пристижныйрак” дип уйлана башлый.**

Ә иң мөһиме адәм баласы өчен үзенең күңеленә туры килгән һөнәр булырга тиеш. Әти-әни, кемнендер кушуы буенча, яисә бу эшнең дәрәҗәсе зур дип кенә уку йортына керү, минемчә, наданлык булыр. Безнең тирә-ягыбызда андыйлар күп. Берничә зур уку йортын тәмамлап, 2-3 диплом белән дә урам себерүчеләр, эшсезлек биржасында торучылар буа буарлык. Әле мәктәп парталары арасында кичә генә утырган кебек. Менә бүген инде “Мөхәммәдия” шәкертләребез, әлхәмдүлиллаһ! Мин бу мәдрәсәдә укуыма шатланып туя алмыйм. Монда бирелгән белемнәрне башка уку йортларында алган гыйлем белән чагыштырып та булмый. КФУ һәм һөнәр көллияте студенты буларак әйтәм. Башка уку йортларында начар диюем түгел. Күпләребез зур уку йортында, ни генә дисәң дә, асылда диплом өчен укый бит инде. Кеше чын мәгънәсендә кеше булып формалашсын өчен дини белемнәрне дөньяви белемнәрдән аермаска тиеш. Кош та ике канатлы, үлчәү дә ике тәлинкәле. Шулай түгелме? Һәр әйберне дә Аллаһы Тәгалә парлы итеп яраткан, хикмәте дә шунда. Нәрсәне генә алсак та, баланс булырга тиеш. “Үз-үзен таныган, Аллаһны да таныган”,-ди. Димәк, безгә үз-үзебезне таныр өчен генә дә күпме фәнни-дөньяви белемнәрне өйрәнергә кирәк. Тарих, биология дисеңме. Коръәндә әйтелә: «Белемсезләр белән белемлеләр чагыштырылмас». Кеше һәрвакыт белемгә омтылса гына, камиллеккә илтүче сукмактан юлга чыгар. “Мөхәммәдия”дә укыган һәр дәресне, эссе көндә суга сусаган кебек «эчәсең». Монда уку дәверендә мин үземнең бу тормыштан ни теләгәнемне, ни көтәсен төшендем. Күземдәге пәрдә алынды. Барлык әйберләрне үз төсе белән, ачык рәвештә күрә башладым. Җаным теләгәнен тапты, дисәң дә артык булмас. Безнең остазларны башкалар белән чагыштырып булмый. Алар безгә иң якын апа-абыйларыбыз кебек. Һәрберсе үзенчәлекле, төпле белемле. Нинди сорау белән генә килсәң дә, җавапсыз җибәрмиләр. Һәрчак ачык чырай белән каршы алалар. Пәйгамбәребез с.г.в. хәдисендә әйтелгәнчә, өстенә китаплар төягән ишәк кебек булмасак иде. Чөнки ишәккә ул китаплардан бернинди файда да юк. Киресенчә барырына комачаулыйлар гына. Безнең алган белемнәребез телебездә генә түгел, күңелләребезгә үтеп кереп, гамәлләребездә чагылыш тапсын. Мин бөтен кешеләргә дә, вакытны әрәм итеп, дөньяда нәрсә теләгәнен белмичә, кайдан килгәнен, кая китәсен белмичә селкенеп йөргәнче, ким дигәндә бер елга гына булса да мәдрәсәләрдә белем алырга кушар идем. Бу караңгы почмактан чыгар өчен бер адым булыр иде. Һәм әлбәттә, ике дөнья бәхетенә ирешер өчен бер кирпеч. Киттекме? Алга! Безне бөек эшләр көтә, ди бит шагыйрь абыебыз да.

.......................................

**СӨМБЕЛ ШӘРИФУЛЛА,**

**“Мөхәммәдия” шәкерте.**

# Мәдрәсәбезнең кадерен белик!

**(Ахыры. Башы 1нче биттә)**

Алар өчен һәрдаим кызыклы чаралар үткәрелеп тора: төрле спорт ярышлары, һәр елны табигать кочагына чыгып, ял итүләр гадәткә кертелгән, һәр уку елының башында гыйлем көне уздырыла, Коръән уку бәйгеләре үтә, сугыш ветераннары белән очрашулар, төрле әдәби кичәләр, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә булышу, мәктәпләрдә наркоманиягә каршы чыгышлар ясау...

Шулай ук чыгарылыш кичәләре дә тирән эчтәлекле, истә калырлык итеп уздырыла. Бүгенге көндәге мәдрәсә белән Габдрахман хәзрәт Хәбибуллин мөдирлек итә. Ул “Ислам диненең кабул ителүенә 1000 ел” исемендәге мәдрәсәне, Россия Ислам Университетын, Мисыр дәүләтенең “әл-Азхар” университетын, Мәскәү институтында читтән торып юридик факультет тәмамлый. Мөдирнең ике ярдәмчесе бар. Уку-укыту эшләре буенча ярдәмче Ранил хәзрәт Талипов Түбән Кама “Рисәлә” мәдрәсәсен тәмамлаган. Бүгенге көндә читтән торып Алабуга педагогия институтында укып дөньяви белем үзләштерә. Тәрбия эшләре буенча ярдәмче Ирек хәзрәт Нуриев Россия Ислам Университетын тәмамлаган, шул ук университетта магистратурада укуын дәвам итә. Мөгаллимнәр төркеме җиде кешедән тора. Башка мәдрәсәләрдән аермалы буларак, биредә укучы шәкертләр шәһәрнең 2нче санлы лицеенда да укыйлар. Биредә алар урта гомуми белем белән беррәттән машина йөртү хокукына ия булып, документ алып чыгалар. Әлеге шәкертләр өчен махсус җәдвәл төзелгән, алар шимбә һәм ял көннәреннән тыш өйләгә кадәр лицейда укып, аннан соң мәдрәсәдә гыйлем алалар. Тулы уку программасын үзләштергән укучыларга шаһәдәтнамә тапшырыла. Аларга имам-хатыйб, шәригать һәм гарәп теле белгечлеге бирелә. Кыскача гына әйткәндә биредә укып чыккан шәкертләр берьюлы өч куянны тоталар: урта һәм дини белем үзләштерәләр, һөнәр алалар. Мәдрәсәнең ачылуына дүрт ел. 2011 нче елда мәдрәсәнең беренче чыгарылышы булды. Кичке бүлекне 80гә якын кеше тәмамлады. Алар арасында нинди генә һөнәр иясе юк: табиблар, мөгаллимнәр, рәссамнар, төзүчеләр, журналистлар, эшчеләр, икътисад-сәнәгать һәм күп төрле башка өлкәләрдә эшләүчеләр... Кичке бүлектә укыту ике төркемгә бүлеп алып барыла: эшләп укучы шәкертләр атнаның ике көнендә кичке якта, ә хезмәттә булмаганнар – атнаның ике көнендә иртәнге якта, өйләгә кадәр укыйлар. Ял көннәрендә оештырылган дәресләрдә яшьләре кечкенәрәк булган шәкертләр укый. Мәдрәсәдә шулай ук имамнарның һәм абыстайларның белемнәрен арттыру курслары да эшләп килә. Алар айга бер тапкыр бирегә җыелалар. Мәдрәсәдә укып чыгып шаһәдәтнамәләр алган укучыларга да гыйлемнәрен тагын да камилләштерергә мөмкинлекләр тудырылган. Алар атнага бер тапкыр мәдрәсәгә килеп укып китә алалар. Мамадыш мәдрәсәсе базасында балалар лагерьлары да (җәйләүләре) үткәрелә. Бу чаралар мәктәп балаларының каникул вакытына туры китерелеп эшләнә. Мәдрәсәнең киләчәккә планнары да зур. Шәкертләргә аерым бинада торак, аерым ашханә, мунча төзү, яшелчә саклый торган склад булдыру, үз-үзен финанс яктан бәйсез итәрлек житештерү тармагын эшләтеп җибәрү, үз умарталыгын тоту, гәҗит, китаплар бастыру өчен типография ясау, барлык уку классларын интерактив такталар һәм кирәкле әсбаплар белән җиһазлау, үз машина паркын булдыру... Укыту программаларына килгәндә дини юнәлештән тыш шәкертләргә профильле һөнәр белгечлеге буенча укыту һ.б. Бу эшләр күп хезмәт таләп итә, әмма Аллаһының рәхмәте зур. Сәбәп кылырга гына кирәк.

Әлбәттә, мәдрәсә эшчәнлегендә четерекле мәсьәләләр дә юк түгел. Алар арасында иң авыры – финанс мәсьәләсе. Шәкертләрнең тору урыннарын, дәресханәләрне, ашханәне тиешле дәрәҗәдә тоту, шәкертләрне өзлексез ашау-эчү белән һәм уку дәреслекләре, башка әсбаплар белән тәэмин итеп тору әлбәттә зур чыгымнар таләп итә... Әлегә мәдрәсә динебез турында кайгыртучы милләттәшләребез, милләтпәрвәр шәхесләребез, иманын җуймаган мәхәллә халкы һәм район администрациясе даирәләрендә эшләүче җитәкчеләребез ярдәмендә көн күрә. Аларга Аллаһы Раббыбыз һәр ике дөньяның бәхет-сәгадәтенә ирешергә насыйп әйләсә иде.

.......................................

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН**

# Гомеребез озын булсын дисәк

**Аллаһы Раббыбыз һәрберебезгә гомеребезне билгеләде. Әмма беребез дә күпме яшиячәген белми.**



Йөрәгенең күпме тибеш ясаячагы да беркемгә дә мәгълүм түгел. Аңа да карамастан, мөселман кешесе бу дөньяда да ахирәттә дә бәхеткә илтә торган төп максатын белә һәм таный. “Әз-Зәрият” сүрәсенең 56 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә бу хакта болай ди: “Мин кешеләрне һәм җеннәрне миңа гыйбадәт кылсыннар өчен яраттым”. Пәйгамбәребезнең хәдис шәрифләреннән билгеле булганча, адәм баласының уртача гомер озынлыгы 60 ел тәшкил итә. Сахих җыентыгында урын алган хәдистә болай диелгән: Пәйгамбәребез әйтте: «Минем өммәтемнең гомер озынлыгы 60 белән 70 ел арасында булачак. Кешеләрнең бик азлары гына шушы чикне үтә алырлар”. Шул ук вакытта Раббыбыз “Хадҗ” сүрәсенең 47 аятендә әйтте ки: “Дөреслектә Раббың каршында бер көн сезнең исәбегездәге мең көн көнгә тиңдер”. Кеше гомерен 60 ел дип алган очракта да Аллаһ каршында бу бары тик бер мизгел генә булып кала. Шушы 60 елдан 20 елын без йокы халәтебездә үткәрәбез. Чөнки кешегә көн саен 8 сәгать йокы тиешле. Бу исә кеше гомеренең өчтән берен тәшкил итә. Моны исәпкә алганнан соң безнең 40 елыбыз кала. Мәгълүм булганча адәм баласының “тәклиф” яки бәлагать чоры 15 яшькә туры килә. Шушы чорга җиткәннән соң гына кеше үз гамәлләре өчен Аллаһ каршында җавап тота башлый. Димәк безнең 25 елыбыз кала. Моның 5 елын без ашап -эчеп һәм башка ихтыяҗларыбызны башкарып үткәрәбез. Ахыр чиктә, барысын исәпкә алганнан соң, безнең карамагыбызда 20 ел вакытыбыз кала. Сүз дә юк, әлеге зекер итеп үткән эшләр–йокы, ашау-эчү, күп төрле ихтыяҗларыбызны канәгатьләндерү һәм башкалар, Аллаһ ризалыгы өчен башкарылсалар, шулай ук гыйбадәткә әвереләләр. Әмма без сөйләшә торган калган 20 елыбыз һәрберебез өчен тагын да кадерле. Бу кыска гына вакытны ничек табышлы итеп үткәргә, аны ничек файдалырак итәргә, сәгатьләрнең, секундларның, атналарның һәм айларның хәер бәрәкәтен ничек арттырырга. Гомумән, гомеребезне озынайтып буламы?

Сүз дә юк, тормышыбызны һәм яшәешебезне бәрәкәтле итеп була. Түбәндәге нәсыйхәтләр моңа ирешергә ярдәм итәр.

**1) Вакытның кадерен белергә өйрәнү.** Безнең һәр мизгелебез Аллаһ ризалыгы өчен булырга тиешле. Болай да бик кыска гомеребезне изгелек кылып, гөнаһлардан тыелып үткәрергә кирәклеге көн кебек ачык. Әгәр дә урамда акча яндырып торган кешене күрсәк, без аны акылсыз дип әйтер идек. Әмма акчаны эшләп табып була. Кызганыч ки, үткән вакытны кире кайтарып булмый. **2) Күркәм холыклы булу.** Күркәм холыклы булу тормышка бәрәкәт өсти һәм җәннәткә якынайта. Юкка гына түгел пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дигән: “Мин бу дөньяга күркәм холыкны тулыландырыр һәм камилләштерер өчен җибәрелдем” **3) Туганлык җепләрен ныгыту**. Пәйгамбәребез әйтте: “Туганлык җепләрен ныгыту малны арттыра һәм гомерне озынайта” **4) Күршеләр белән яхшы мөгамәләдә булу.** Пәйгамбәребез әйтте: “Туганлык җепләрен ныгыту, күркәм холык һәм күршеләргә яхшы мөгамәләдә булу малны арттыра һәм гомерне озынайта” **5)Җәмәгать белән намаз уку.** Пәйгамбәребез әйтте: “Җәмәгать намазы аерым укыган намазга караганда 27 мәртәбә артыграк” (Бухари) Димәк, бер ел буе җәмәгать намазларын калдырмау 27 елга арттыграк яшәгәнгә бәрабәр. **6)Өйдә нәфел намазларны торгызу.** Пәйгамбәребез әйтте: “Кеше күрмәгән җирдә укылган нәфел намазы, кеше күз алдында укылган нәфел намазына караганда 25 мәртәбә артыграк.” (сахих аль-Җәмигъ) **7)Җомга намазында даимчылык кылу.** Пәйгамбәребез әйтте: «Кем дә кем җомга көнне тәһарәт алса, үзенең гаиләсен дә җомга намазын укырга үгетләсә, соңыннан җәяүләп мәчеткә юнәлсә һәм имамга якын утырып сөйләшмичә вәгазь тыңласа, аның һәр адымы өчен ураза белән һәм төнге намазлар белән үткәргәндәй өстәмә бер ел язылыр.» (сахих аль-Җәмигъ) **8) Хаҗ гыйбадәтен үтәү.** Пәйгамбәребез әйтте: «Харам мәчетендә укылган намаз башка мәчетләрдә укылган намаздан 100000 тапкыр артыграк, Мәдинә шәһәрендә пәйгамбәребез мәчетендә укылган намаз башка мәчетләрдә укылган намазлардан 1000 мәртәбә артыграк, «Ал-Акса» мәчетендә укылган намаз 500 мәртәбә артыграк». Мәсәлән, әгәр дә сез көненә 12 рәкәгать нәфел намазы укыйсыз икән, елына ул 4320 рәкәгать тәшкил итәчәк. Әмма Мәккәдә Харам мәчетендә 2 рәкәгать намаз укуың 46 ел Аллаһка гамәл гыйбадәттә булгансың дигән сүз. **9) Мәчеттә иртәнге намазны укыганнан соң кояш чыкканчы Аллаһны зекер итеп утыру.** Пәйгамбәребез әйтте: «Кем дә кем, иртәнге намазын мәчеттә укып, соңыннан кояш чыкканчы Аллаһны зекер итсә һәм кояш чыкканнан соң ике рәкәгать намаз укыса, аңа Хаҗ һәм Гомрә кылу савабы булыр» (ат-Тирмизи) **10) Дин дәресләрен алуда даимчылык кылу.** Пәйгамбәребез әйтте: «Кем дә кем, гыйлем өйрәтү яки гыйлем алу максаты белән өеннән чыгып китсә, Аллаһы Тәгалә аңа Хаҗ кылу савабын бирер» (Сахих таргиб ва тархиб). **11) Азан әйтү. Пәйгамбәребез әйтте**: «Дөреслектә Аллаһ һәм аның фәрештәләре намазның беренче сафларында укучыларга бәрәкәт теләп торалар. Мөәзиннәрне гөнаһлары азанны сузып әйтү микъдарында кичерелер. Аны ишеткән һәркем аны тәсдыйк кылыр. Мөәзингә аның белән бергә намаз укучыларның әҗер саваплары ирешер”. **12) Ураза тоту**. Пәйгамбәребез әйтте: “Кем дә кем, Рамазан аенда ураза тотып соңыннан шәүвәл аеның 6 көнендә ураза тотса, шул кеше ел буе ураза тоту савабын алыр” (Мөслим) **13) Ураза тотучыны ифтар кылдыру.** Пәйгамбәребез әйтте: “Ураза тотучыны ифтар кылдыручыга, ураза тотучының савабы кимемәгән хәлдә, аңа да әлеге әҗер-савап ирешер”.(сахих аль-Җәмигъ) **14) Кадер кичен гыйбадәттә үткәрү.** Аллаһы Тәгалә әйтте: «Кадер киче мең айдан да хәерлерәктер» («ал-Кадер» сүрәсе, 3 нче аять) **15) Мөселманнарга ярдәм итү, аларның мәшәкатьләрен хәл итүдә катнашу.** Пәйгамбәребез әйтте: «Аллаһ каршында иң сөекемле кеше–мөселманнарга иң файда китергәнедер. Аллаһ каршында иң сөекемле эш–мөселманга ирештерелгән шатлыктыр: аның кайгысын уртаклашу, әҗәтен түләргә ярдәм итү, мохтаҗ булса, аңа ризык бирү. Мөселман кардәшең белән янәшәдә булу, аңа ярдәм кулы сузу ай буе мәчеттә игътикаф кылудан да хәерлерәктер. Кем үзенең ачуын тыя алды Аллаһ аның кимчелеген яшерер. Кем ачуланырга сәбәпләр булып та сабыр итеп кала белде, шул кыямәт көнендә күңелендә тынычлык табар. Кем үзенең кардәшенә ярдәм итәргә ашыкты, Аллаһы Тәгалә аның аякларын кыямәт көнендә нык кылыр. Серкә балны бозган кебек, күркәм булмаган холык та гамәлләрне бозадыр.»

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН**

## Викторина жаваплары

# Җиңүчеләр билгеле

**Газетабызның 14 нче санында басылган викторина җаваплары**
1) Хәзрәти Биләл.
2) Куба мәчете.
3) Таяк еланга әйләнә, нурлы кул, Нил елгасы канга әйләнә, бөтен җир бакалар белән тула, диңгез ачыла, Тур тавында Аллаһ белән сөйләшә, сыер койрыгы белән мәетне сугып терелтүе, су баса, бет тарала.
4) Хәзрәти Гали.
5) Җәбраил галәйһис-сәлам
6) Ур шәһәре, Гыйрак җирлеге.
7) Мәдинә шәһәрендә, хиҗрәтнең 10нчы елында "Ән-Наср" сүрәсе.
8) Ясриб.
9) Рамазан аенда.
10) Дүрт мәртәбә.
11) Ильяс һәм Әльясәгъ.
12) Юныс, Һуд, Йосыф, Ибраһим, Мөхәммәд, Яхья, Нух.
13) Һиҗри 2 нче ел.
14) Рукн хәҗәру ал-Әсвәд, рукн Ямәни, рукн Гыйраки, рукн әш-Шәми.
15) Әбү Хөрәйра, 5300 хәдис риваять иткән.
16) Кырмыска һәм Удод кошы.
17) 17нчы елда хәзрәти Гомәр тарафыннан.
18) "Әл–Кәхф" сүрәсе 50 нче аять.
19) Җәмәрат.
20) "Вәл гаср".

**Җиңүчеләр: ГӨЛКӘЙ ӘГЪЛИУЛЛИНА һәм Урта Кирмән мәктәбенең 9нчы сыйныф укучысы АЛИНӘ МӨГЪТӘСИМОВА.**

## Конкурска

# Юасы бар гөнаһны

Бар иде динсез чаклар,
Ходай соң, ничек аклар?
Мәңгегә килгән кебек
Бугаз киергән чаклар.
Гөнаһлар күп җыелган,
Иманыбыз җуелган.
Тормышка яраклашканбыз
Торып, аның җаеннан.
Гөнаһлар күп җыелган
Аны ничек юарга?
Гөнаһсыз яшәү өчен
Кирәк, кабат туарга.
Ходай кичерә диләр,
Башын игән колларын,
Изге юлга чакыра
Кызларын һәм улларын.
Адаштык та, буталдык
Аермадык агын, карасын.
Иман белән үтик инде
Калган гомер арасын.
Ходай йорты балкып тора,
Манарада–көмеш ай.
Дөньялар тыныч булсын,
Рухи тормыш булсын бай.
...............................
**РАФАИЛ ФӘЛӘХОВ.**

**Түбән Тәкәнеш авылы**

# Ярлыкачы, Ходам!

Тормыш авырлыгын
зар елашып,
Ялганнарга кадәр
җитәбез.
Ярлыкачы, Ходам,
ярлыкачы,
Туры юлда
түгел икәнбез.
Күрше-күлән хәлен
белмичә дә,
Үзебезне үзебез
биклибез.
Ярлыкачы, Ходам,
ярлыкачы,
Ахры, туры юлда
түгелбез.
Балаларны яклап,
узындырып,
Эш күрсәтми
тәрбия итәбез.
Ярлыкачы, Ходам,
ярлыкачы,
Тагын кире юлдан
китәбез.
Хезмәт, хөрмәт,
сабыр итә белү;
Уңай сыйфат булсын
синдәге.
Аллаһыдан гафу
сорый белү–
Мөселманның
асыл бизәге.
...............................
**ГӨЛНУР ВАСЫЙЛОВА**

Мамадыш шәһәре

## Сорау-җавап

**Кеше берни эшләмәсә дә, аның белән төрле хәлләр булып тора. Мәсәлән, мин матди хәлемнең яхшыруын телим, әмма моның өчен берничә гамәл кылмыйм. Шул ук вакытта якыннарым һәм күршеләрем байый, аларның тормыш дәрәҗәсе күтәрелә бара. Димәк, минем язмышым шундый. Ә башкаларныкы андый түгелме? Мин моның белән болай гына кызыксынмыйм. Бу хактагы белем миңа гына түгел, башкаларга да үз тормышларын оештырырга ярдәм итәр иде. Эльмира**

–Без язмышка каршы килә алмыйбыз, ә Хак Тәгаләнең рәхмәте белән үз язмышыбызны үзебез төзибез. Ягъни, теге яки бу эшне үзебез кылабыз. Ә бу һәр көнне башкарыла торган гамәл: әйтик, син озаграк йокларга телисең, тик иртә торасың, чөнки күбрәк эшләп каласың бар. Син күбрәк ашарга телисең, әмма үзеңне чиклисең, чөнки яшьлегеңне һәм эшкә сәләтеңне саклыйсың килә. Син кем беләндер ачуланырга телисең, әмма моны эшләмисең, чөнки ул гамәлнең файдасыз һәм нәтиҗәсез икәнлеген беләсең. Син күп көч һәм дулкынланулар китерүче җаваплылыкны үзеңә алырга теләмисең, шулай да аны үзеңә аласың һәм никадәрле авыр булмасын, ул эшне ахырына кадәр җиткерергә тырышасың. Тормышта Аллаһ тарафыннан билгеләнгән һәм һәркем өчен бертигез булган закончалыклар бар. Бөтен мәсьәлә кешенең рухи, гыйльми һәм физик яктан никадәрле тырышлык куюына кайтып кала. Бу тырышлыкны ул бер атна эчендә генә түгел, уннарча еллар буена куярга тиеш. 30 ел эчендә организмның кайбер әгъзалары тузгач, физик яктан чыныгу һәм вакытында ял итү аеруча мөһим төс ала. Моны исә кыйммәтле спотзалдан башка да эшләп була.
Максат һәм бурычларны дөрес итеп куя белергә генә кирәк. Калганнарын сез үзегез дә миннән начар белмисездер, дип уйлыйм. Иң мөһиме-җиңүгә омтылыш һәм Раббыбызга ышаныч, чөнки Аның теге яки бу уңышны казанган кешеләргә «Булсын!» дип әйтүе дә җитә.

**Сораугa җавап umma.ru сайтыннан алынды**

## Укырга чакырабыз

# Мамадыш мәдрәсәсенә рәхим итегез!

Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары Диния Нәзарәте каршындагы Мамадыш мәдрәсәсе 2012-2013 уку елына шәкертләр туплый.
Белгечләр әзерләү көндезге һәм кичке уку рәвешендә алып барыла.
Көндезге бүлеккә яше 14тән дә ким булмаган егетләр кабул ителә. Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көненә өч тапкыр ашау-эчү белән тәэмин ителәләр. Уку вакыты – өч ел. Урта белем алу икенче санлы лицей базасында алып барыла. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң шәкертләргә квалификация комиссиясе карары нигезендә тиешле белгечлек алу турында диплом бирелә.
Укырга керү өчен кабул итү комиссиясенә түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

1) **Гариза**
2) **Белем турында таныклык**
3) **086-формасында сәламәтлек турында белешмә**
4) **Паспорт (копия)**
5) **3х4 үлчәмендә 4 фотосурәт**
6) **№26 формасында шәхси медицина картасы**

**Документлар 30 августка кадәр кабул ителә.**

*Намаз укырга өйрәнергә һәм дин белемен үзләштерергә теләүчеләр өчен мәдрәсәдә кичке уку бүлеге һәм читтән торып уку бүлеге эшли. Бу бүлекләргә хатын-кызлар һәм ир-егетләр кабул ителә. Яшь чиге куелмаган. Безнең адрес: Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, М. Җәлил урамы 8/28,*
**Телефоннар: 3-19-17, 89172802391**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.
Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.
Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета "Татмедиа" ААҖнең Мамадыш муниципаль районы"Нократ" мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 100 данә.**